**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**

**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Совет города Арск**

**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәре Советы**

**КАРАРЫ**

**«7» октябрь 2019 ел** **№ 127**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына яраклаштырып, Арча шәһәре башкарма комитетының «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» 2019 елның 3 нче октябрендәге 39 номерлы карары, Арча шәһәре Советының «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» 2019 елның 3 нче октябрендәге 126 номерлы карары нигезендә, Арча шәһәре Советы КАРАР бирде:

1. 2019 елның 24 нче ноябренә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
“2020 елда «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 1 нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?”

1. Шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру:
- урам яктырткычларын урнаштыру һәм алыштыру, изоляцияләнгән чыбык сузу һәм тышкы яктырту баганалары урнаштыру;
-Арча ш.: Юл тыкрыгы, Күпфункцияле Үзәктән Г.Салихов урамына кадәр квартал юлы; Г. Ахунов ур.; Тимер юл ур.; М. Галәү ур.; Ватан ур.; Фабрика ур.; Пионер ур.; Май т.; М. Горький ур.; Зур ур.; Наратлы ур.; Астрономия ур.; Бирәзә т.; Г.Салихов ур.; Коммуна ур.; «Казан-Малмыж» автомобиль юлыннан Ф. Әмирхан урамына кадәр квартал юлы; Кәримов ур.
- Төбәк-Чокырча авылы: Бакча урамы.
- каты көнкүреш һәм коммуналь калдыкларның контейнер һәм бункер мәйданчыклары һәм аларга керү юллары нигезләрен һәм киртәләрен урнаштыру:
- Арча ш.: Совет мәйданы; Зәйнуллин ур.; Җиңүнең 65 еллыгы ур.; Г. Тукай ур. (1 нче квартал юлы); Г. Сафиуллин ур. (1 нче квартал юлы); С. Сәйдәшев ур.; Коммуна ур.; Кызыл Бистә ур.; Түбән урам-1; Түбән урам-2; Түбән урам-3; М. Гафури ур.; Тимер юл ур. (2 шт.);
- Иске Айван авылы: Түбән ур.; Югары ур.

2. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге:
- юл-урам челтәренә вак таштан нигез һәм юл катламы салу:
- Арча ш.: Маршал Жуков ур. (15 нче йорттан 17 нче йортка кадәр); Күпер ур. (31 нче йортка керү юлы); Май т.; Май ур.; Комсомол ур. (78 нче йорт); Комсомол урамы (АЗС арты); Кәримов урамыннан Ф. Мансуров урамына кадәр

квартал юлы; Г.Бәширов ур. 50 нче йорттан 54нче йортка кадәр; Себер тракты ур.; Г. Салихов ур.; Сибгатуллин урамыннан Маяковский урамына кадәр квартал юлы; Сибгатуллин урамыннан Яшьләр урамына кадәр квартал юлы; Сибгатуллин урамыннан Космонавтлар урамына кадәр квартал юлы; Бирәзә ур.; Бирәзә урамыннан К. Тинчурин урамына кадәр квартал юлы;

-Зур Бирәзә авылы: Арча-Олы Әтнә автомобиль юлыннан зиратка кадәр дамба; Үзәк урамнан Г.Тукай урамына кадәр квартал юлы;

- Васильева Божа авылы: Магистраль ур.;

- Күпербаш авылы: Мәктәп ур.; Яр буе ур.; Мичурин урамыннан Яр буе урамына кадәр квартал юлы;

- Төбәк-Чокырча авылы: Дан ур.; Мәктәп ур.; Бакча ур.

3. Җирлеккә кергән торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантларын урнаштыру: Арча ш.: Н. Сафин ур.; Шаляпин ур.; Зәйнуллин ур.; Ш. Күлтәси ур.; Агрономия ур.; Җиңү ур.; М. Гафури ур.; Маяковский ур.; Яшьләр ур.; Островский ур.; Пионер ур.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Арча шәһәре Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә кирәк.

ӘЙЕ ЮК

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт; Арча шәһәре, Һ.Такташ урамы, 58 йорт; Арча шәһәре, Өрәңгеле урам, 4 йорт; Арча шәһәре, Банк урамы, 2а йорты.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы в.б.,
Арча шәһәр Советы рәисе в.б. Г.Х.Нигъмәдҗанова